Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР №8**

Биектау авылы 2024 елның 07 нче октябре

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә түләү мәҗбүри булган салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык төзелмәләре яисә корылмалары;

2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент;

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортлар өлешләре;

- төгәлләнмәгән төзелеш объектлары, әгәр мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса;

- составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

3.1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарны физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

3.2) Салым ташламасы салым түләүче һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым түләүче милкендәге салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы билгеләнгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә салым түләүче сайлаган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;
2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;
3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 маддәсендәге 1 өлешенең 14 пунктында күрсәтелгән бина яисә корылма;
4) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 маддәсендәге 1 өлешенең 15

пунктында күрсәтелгән хуҗалык төзелмәсе яисә корылма;

5) гараж яисә машина урыны.

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 маддәсендәге 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан машина урыннары гаражларыннан гайре.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукынраслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр үз теләге белән тапшырыла.

Салым органына сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым түләүче салым чоры булган елның 1 ноябреннән соң, күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы бирелә торган салым салу объектын үзгәртеп, төгәлләштерелгән (анықланган) хәбәрнамә тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырмаса, салым ташламасы һәр төрдәге салым салуның максималь исәпләнгән суммасы булган бер объектына карата бирелә.

4) Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2%;

5) 2025 елга (2026 елга һәм аннан соңгы елларга 2 %) түбәндәгеләргә карата 1,2% процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсенең 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсенең 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,5 процент;

7) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

3. Көчен югалткан дип танырга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июне «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 15 карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл

җирлеге Советының 2015 елның 15 октябре «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 2-1 карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 октябре «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 15 карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябре «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 17 карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 июне «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябре «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гы 11 карарын;

4. Әлеге карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасының 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булуын билгеләргә.

5. Карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х.Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 нче йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы<br>
Балык Бистәсе муниципаль районы<br>
Биектау авыл җирлеге башлыгы Р.К.Сахапов